ГЛАВА БАЛТАСИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАЛТАЧ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОН БАШЛЫГЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«15» январь 2021 ел № 13

**Балтач муниципаль районында**
**Туган телләр һәм халыклар бердәмлеге елын үткәрү турында**

Балтач муниципаль районында яшәүче халыкларның туган телләрен, мәдәниятен һәм традицияләрен саклау һәм үстерү, күпмилләтле халыкның бердәмлеген ныгыту максатларында, Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы башлыгы карар бирә:

1. Балтач муниципаль районында Туган теллләр һәм халыклар бердәмлеге елын үткәрү буенча эшче төркем составын 1 нче кушымта нигезендә расларга.

2. Туган телләр һәм халыклар бердәмлеге елына багышланган район чаралары планын 2 нче кушымта нигезендә расларга.

3. «Моңлы телем, нурлы телем – Туган тел!» район әдәби-сәнгать смотр-конкурсы Нигезләмәсен 3 нче кушымта нигезендә расларга.

4. Тәкъдим итәргә:

4.1 Авыл хуҗалыгы предприятиеләре, оешмалар, учреждениеләр һәм муниципаль берәмлекләр (авыл җирлекләре) җитәкчеләренә Туган телләр һәм халыклар бердәмлеге елына багышланган район чараларын әзерләүдә катнашырга (транспорт, сәхнә костюмнары, декорация, музыкаль аппаратура һ.б.).

4.2 «Татмедиа» ААҖ филиалы «Хезмәт» газетасы редакциясенә (Закиев В.М.), «Кайтаваз» ТРК муниципаль учреждениесенә (Маннапова Г.С.) Балтач муниципаль районы учреждениеләре, муниципаль берәмлекләре (җирлекләре) арасында Туган телләр һәм халыклар бердәмлеге елына багышланган район мәгариф, мәдәни-массакүләм һәм спорт чараларын үткәрүнең барышын яктыртырга.

4.3 Балтач муниципаль районының финанс-бюджет палатасына (Ильясов Р.М.) Балтач муниципаль районы учреждениеләре, муниципаль берәмлекләре (җирлекләре) арасында Туган телләр һәм халыклар бердәмлеге елына багышланган район мәгариф, мәдәни-массакүләм һәм спорт чараларын үткәрүгә чыгымнарны, чираттагы финанс елына район бюджетында күрсәтелгән максатларга каралган акча чикләрендә, Балтач муниципаль районы бюджеты акчалары хисабына финанслауны гамәлгә ашырырга.

5. Туган телләр һәм халыклар бердәмлеге елына багышланган районның мәгариф, мәдәни һәм спорт чараларын Татарстан Республикасы Балтач

муниципаль берәмлекләре (җирлекләре), учреждениеләр арасында үткәрүне Балтач районы башкарма комитетына оештыруны тәкъдим итәргә.

6. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Балтач район башкарма комитеты җитәкчесе урынбасарына йөкләргә.

Балтач муниципаль
район башлыгы Р.Р.Нотфуллин